| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ТЕЛӘЧЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| РАСПОРЯЖЕНИЕ | | БОЕРЫК |
| «10» октябрь 2022г. | с. Тюлячи | № 230 |

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 сентябрендәге 186 номерлы «Теләче» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең «Дулкын» ябык йөзү бассейнының түләүле хезмәт күрсәтү бәяләре прейскурантын раслау турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләүне игълан итү турында» Указы нигезендә, Теләче муниципаль районы муниципаль мөлкәтен нәтиҗәле файдалану максатларында,

1.Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 сентябрендәге 186 номерлы «Теләче» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең «Дулкын» ябык йөзү бассейнының түләүле хезмәт күрсәтү бәяләре прейскурантын раслау турында» боерыгына, кушымтаны түбәндәге эчтәлектә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетынын «14»
сентябрь 2022 № 186
боерыгынын 1 номерлы
кушымтасы

«Теләче» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең «Дулкын» ябык йөзү бассейнының түләүле хезмәт күрсәтү бәяләре прейскуранты

| Хезмәтнең атамасы | 1 сәгать булу бәясе (45 минут шөгыльләнү, 15 минут душ һәм киенү) |
|---|---|
| Бассейнга бер тапкыр бару: | |
| Зурлар өчен (18 яшьтән) | 140 сум |
| 18 яшькә кадәрге затлар өчен | 70 сум |

| | |
|---|---|
| ( шәхесне таныклый торган документ булганда) | |
| Картлык буенча яки тиешле еллар эшләгән өчен пенсия таныклыгы булган пенсионерлар өчен | 70 сум |
| Күпбалалы гаиләләр әгъзаларына (таныклык күрсәткәндә) | 40 сум |
| Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр (II һәм III группа инвалидлар) | 70 сум |
| Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләрендәге балалар | Түләүсез |
| 1 ата яки ана һәм 1 бала ( 3 яшьтән 7 яшькә кадәр ике бассейнда) | 140 сум |
| Инструктор белән индивидуаль дәресләр 18 яшьтән зурраклар өчен зур бассейнда, 45 минут | 1 тапкыр шөгыльләнү өчен 400 сум |
| Инструктор белән индивидуаль дәресләр ике бассейнда 18 яшькә кадәр затлар өчен, 45 минут | 1 тапкыр шөгыльләнү өчен 300 сум |
| Инструктор белән төркемле шөгыльләнү (өлкәннәр 15 кешегә кадәр, 45 минут) | 1 тапкыр шөгыйльләнү өчен 250 сум |
| Инструктор белән төркемле шөгыльләнү 7 яшьтән 18 яшькәчә - 15 кешегә кадәр | 1 тапкыр шөгыльләнү өчен 150 сум |
| Сауна (30 минут) | 100 сум |
| Искәрмә: тапшырылган сертификатлар урынына | абонемент бирелә |
| Вакытлыча алып тору | |
| Сөлге | 50 сум |
| Йөзү өчен билгә жайланма | 50 сум |
| Йөзү өчен такта | 50 сум |
| Ластлар | 50 сум |
| Сланецлар | 30 сум |
| Калкавыч | 30 сум |

Искәрмә: күчерү юлы белән түләү мөмкин. Ташламалар гаилә әгъзасын Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча чакыруны раслаучы таныклык, хәрби комиссариатның белешмәсен күрсәткәндә бирелә.».

2. Әлеге боерык аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И. Х. Хәмидуллин